**Район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Илһам Фидәил улы Гайнетдинов чыгарылыш сыйныфы укучыларын бәйрәм белән котлады**

«Районыбыз укучыларының уңышлары укуда да, сәнгатьтә дә башка юнәлешләрдә дә бик күп. Хәзерге укучылар турында сүз алып барганда, волонтёр, активистлар дигән төшенчәләрне дә еш ишетергә һәм алар башкарган игелекле эшләрнең шаһитләре булырга туры килә. Тирә-юньгә мәрхәмәтлелек, якты киләчәккә өмет бүләк итүче волонтёрлар, мәктәп тормышын тагын да кызыклы вакыйгаларга баетучы активистлар үзләре дә сизмәстән, район, республика кысаларында үтә торган вакыйларның уртасында кайныйлар» - дип билгеләп узды җитәкче урынбасары. Мәктәп еллары буена волонтёрлык юнәлешендә актив катнашучы чыгарылыш сыйныф укучыларына да бүгенге бәйрәм кысаларында иң ихлас рәхмәт сүзләре яңгырады.

